**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәсгут авыл җирлеге авыл җирлеге Советы**

Мәсгут авылы № 138 «23» сентябрь 2019 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Мәсгут авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Сез 2020 елда үзара салым кертүгә килешәсезме?

Мәсгут авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 400 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметергә, аны 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум итеп билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Мәсгут авылы 8 Март, 1 Май, Г. Баһманов урамнары юлларына чуерташ - вак таш җәю;

- Мәсгут, Яхшы-Бай авылларында татар теленә тәрҗемә ителгән юл күрсәткечләрен сатып алу (әзерләү);

- Мәсгут, Яхшы Бай авылларында «Сабантуй», «Яңа ел», «Җиңү көне», «Халыкара хатын-кызлар көне», «Ватанны саклаучылар көне» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;

- ПУМ 4853 төяү-урып-җыю машинасы өчен КУН-10 төягеч сатып алу (82.1Беларусь тракторы базасында)

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәсгут авылы, Дуслык ур., 12 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.




Рәис: Габдрахманов Э.Ә.